| | | |
|---|---|---|
| СОВЕТ<br>АЛЕКСЕЕВСКОГО<br>ГОРОДСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>АЛЕКСЕЕВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>АЛЕКСЕЕВСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ<br>АЛЕКСЕЕВСК<br>ШӘҺӘР ҖИРЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |
| РЕШЕНИЕ | | КАРАР |
| 29.04.2019 | п.г.т. Алексеевское | № 197 |

**«Татарстан Республикасы**
**Алексеевск муниципаль районы**
**Алексеевск ш.т.б. җирләреннән файдалану**
**һәм җирлекне төзү кагыйдәләрен раслау турында”**
**Алексеевск муниципаль районы Алексеевск шәһәр җирлеге**
**Советының 29 гыйнвар, 2011 ел, 108 нче карарына**
**үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе шәһәр төзү кодексының 31-33 нче маддәләрен, “Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында”гы 6 октябрь, 2003 ел, 131-ФЗ санлы Федераль законны, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Алексеевск шәһәр җирлеге муниципаль берәмлеге Уставын кулланып эш итеп, 19 апрель, 2019 елда халык алдында тыңлаулар йомгакларын (тәкъдимнәрне) исәпкә алып,

**Алексеевск шәһәр җирлеге Советы карар бирде:**

1. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Алексеевск ш.т.б. җирләреннән файдалану һәм җирлекне төзү кагыйдәләренә Алексеевск шәһәр җирлеге Советының 29 гыйнвар, 2011 ел, 108 нче Карары белән расланган түбәндәге үзгәрешләрне кертергә: җирдән файдалану һәм җирлек төзү кагыйдәләренең шәһәр төзүне зоналарга бүлү картасын үзгәртергә:

- Алексеевск ш.т.б.ның төньяк өлешеннән Октябрь урамы буйлап, атап әйткәндә (картаны төньякка ориентацияләгәндә) : Октябрь урамының сул ягыннан, Төньяк урамы киселешеннән төньяккарак Р-1 территориаль зонаның гомуми мәйданының 0,6113 гектарлы бер өлешен ( гомуми файдаланудагы яшелләндерелгән территорияләр зонасы) Р-2 территориаль зонага (рекреацион-ландшафт территорияләре зонасы) үзгәртергә.Әлеге территориаль зонаны үз эченә алучы җир кишәрлекләренең кадастр саны: 16:05:010402:148. Әлеге территориаль зона урнашкан кадастр кварталы: 16:05:010402 (кушымта).

2.Әлеге карарны Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында, мәгълүмати-телекоммуникацион Интернет челтәрендә, шулай ук Алексеевск шәһәр җирлеге мәгълүмати стендында урнаштырырга.

3. Карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешенә контрольлек итүне Алексеевск шәһәр җирлеге башлыгы урынбасары О.В.Зубриловага йөкләргә.

**Алексеевск муниципаль районы**
**Алексеевск шәһәр җирлеге башлыгы,**
**Совет рәисе** **С.А. Демидов**

Алексеевск шәһәр җирлегенең
19 апрель, 2019 ел, 197 нче
карарына кушымта

